| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**муниципального образования**<br>**«поселок городского типа**<br>**Актюбинский» Азнакаевского**<br>**муниципального района** | | **Азнакай муниципаль районы**<br>**«Актүбә шәһәр тибындагы поселок»**<br>**муниципаль берәмлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |
| ул. Губкина, д. 24, п.г.т. Актюбинский,<br>Азнакаевский муниципальный район,<br>423304<br>тел. (факс): (85592) 3-16-63<br>E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru | | Губкин урамы, 24 йорт, Актүбә ш.т.п.,<br>Азнакай муниципаль районы, 423304<br>тел. (факс): (85592) 3-16-63<br>E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru |


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» июль 2023 ел № 4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы бистә җирлеге Советы 15.12.2022 елның № 55 карары белән расланган (30.03.2023 №18 карар редакциясендә) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе төзелеш кодексының 31 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы “Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советының 15.10.2018 № 45 карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы бистә җирлегендә халык тыңлаулары оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә таянып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы бистә җирлеге Советы 15.12.2022 елның № 55 карары белән расланган (30.03.2023 №18 карар редакциясендә) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлек биләмәләреннән файдалануны һәм төзелешләрне үз эченә алган үзгәрешләр кертү турында проект буенча ачык тыңлаулар билгеләргә:

- инженерлык инфраструктурасының территориаль зонасы (И) № 4-1 исемен И (И-Ф) зонасы регламентына ярашлы рәвештә җирләрне чынлыкта куллану территориясенә үзгәртергә.

2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы бистә халык тыңлауларын оештыручы тарафыннан җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссияне;

- үткәрү вакыты – 2023 елның 01 августтан 2023 елның 22 августка кадәр 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;

- үткәрү урыны – Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Актүбә ш. т. б., Губкин ур., 24 йорт;

- фикер алышына торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә ала торган адрес: Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Актүбә ш. т. б., Губкин ур., 24 йорт, Башкарма комитеты.

3. Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссиягә:

- гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар нигезендә билгеләнгән срокларда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;

- ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә бастырырга.

4. Әлеге карарны һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» авыл җирлеге җир биләмәләреннән файдалану һәм муниципаль берәмлек төзелеше кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектын Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Башлык А.Л. Севостьянов